ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«НОВОИШТЕРЯКСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Заречная ул., дом 25,
поселок Новочершилинский,
Лениногорский район, 423274

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЯҢА ИШТИРӘК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Заречная урамы, 25 нче йорт,
Яңа Чыршылы поселогы,
Лениногорск районы, 423274

Тел./факс: (8-85595) 3-04-32, Nchersh.Len@tatar.ru, leninogorsk.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19.11.2020 ел № 6

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 31 июлендәге 8 номерлы карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

РФ Хөкүмәтенең «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 4 сентиябрендәге 1355 номерлы карары нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Яңа Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Лениногорск муниципаль районы «Яңа Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 31 июлендәге 8 номерлы карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 19.11.2014 ел, №1221 карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләренең 20 пунктында каралган карарлар вәкаләтле органнар тарафыннан кабул ителгән документларга түбәндәгеләр кирә:»;

2. 2.6 пунктны түбәндәге эчтәлекле 10 абзац белән тулыландырырга:
«3 пунктта күрсәтелгән документ мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) электрон имзасы белән раслана, аның төре «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" Федераль законның 21_1 статьясындагы 2 өлеше нигезендә билгеләнә»;

3. 1.5 пунктының 8 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «адресация объектының идентификация элементлары» - җир участоклары номерлары, башка адресация объектларының типлары һәм номерлары".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Яңа Иштирәк авылы, Центральная, 7 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында “Авыл җирлекләре” бүлегендә (leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Яңа Иштирәк авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Г.Р.Мәүлетова